Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№24 (37)

13 сентябрь 2012 ел

## • Универ хәлләре

10 сентябрь көнне КФУның **ЯР ЧАЛЛЫ ФИЛИАЛЫНА** эш визиты белән **«АЛАБУГА» ИКЪТИСАДИ ЗОНАСЫ ВӘКИЛЛӘРЕ КИЛДЕ**. Белгечләр студентларга хезмәт базарында нинди һөнәр ияләренең кирәклеген, карьера үсешенә ничек ирешергә, махсус икътисади зонага эшкә урнашуның өстенлекләре кебек сорауларга җавап табарга ярдәм итте. Икътисад зонасы җитәкчелеге студентларның анда стажировка үтеп, чит илдә магистр дәрәҗәсен алу мөмкинлегенең зур булуын да билгеләп үтте, ә уку дәүләт хисабыннан.

• • • •

10-14 сентябрь көннәрендә **КФУНЫҢ ФИЗИКА ИНСТИТУТЫНДА АВСТРИЯ ГАЛИМЕ РУДОЛЬФ ГРИММ КУНАК БУЛДЫ**. Дәрәҗәле кунак Австрия фәннәр академиясенең квант оптикасы һәм квант мәгълүматлары институты директоры, Инсбург эксперименталь физика институтында профессор булып тора.

• • • •

КФУның **ПЕДАГОГИКА ҺӘМ ПСИХОЛОГИЯ ИНСТИТУТЫ ТАРАФЫННАН КӨНБАТЫШ МИЧИГАН УНИВЕРСИТЕТЫ** (АКШ, Мичиган штаты, Каламазу шәһәре), **УКЫТУ СИСТЕМАЛАРЫН ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ** (Томск шәһәре), **КУЗБАСС ДӘҮЛӘТ ПЕДАГОГИКА АКАДЕМИЯСЕ** (Новокузнецк шәһәре) белән **ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ИТҮ ТУРЫНДАГЫ КИЛЕШҮГӘ КУЛ КУЕЛДЫ**. Россия Федерациясендәге һәм АКШтагы педагогика, шәхеснең иҗади үсеше кебек өлкәләр буенча чагыштырма-тикшеренү эшләре үткәрү бергәләп эшләүнең төп максаты.

• • • •

Иртәгә 9 сәгать 30 минутта КФУның Бутлеров исемендәге аудиториясендә **«СПЕКТРАЛЬ СИСТЕМАЛАР» КОМПАНИЯСЕ** аналитик җиһазлар ясый торган дөньяның алдынгы җитештерүчеләре белән берлектә «Биомедицина һәм фәнни-тикшеренү лабораторияләре өчен заманча җиһазларны һәм чиста зоналарны валидацияләү» дигән **ФӘННИ-ГАМӘЛИ СЕМИНАР** үткәрә.

• • • •

18 сентябрь көнне «УНИКС»ның зур концертлар залында беренче курс студентлары өчен **«СТУДЕНТ ТОРМЫШЫ БУЙЛАП ЭКСКУРСИЯ»** дип исемләнгән концерт үтәчәк. Чарада университетның иҗади тормышы белән якыннан танышырга мөмкин. Өлкән курс студентлары иң яхшы саналган чыгышлары белән «иҗади багажның» ни дәрәҗәдә бай икәнен күрсәтәчәк.

• • • •

18 сентябрьдә сәгать көндезге бердә **THOMSON REUTERS КОМПАНИЯСЕ** «Галимнәр бренды: синең цитатаң кулланылышка керсен өчен өчен нишләргә?» дигән **СЕМИНАРДА КАТНАШЫРГА ЧАКЫРА**. Аны химия фәннәре кандидаты, «Thomson Reuters»ның клиентларны өйрәтү һәм аларга булышу буенча белгеч Сергей Парамонов җитәкләячәк. Керү бушлай. Семинар ике сәгать дәвам ителер, мөгаен. Соңыннан катнашучылар өчен кофе-брейк оештырылачак.

• • • •

Яңа 2012-2013 уку елында Кече филология һәм сәнгать институтында лингвистика, **ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ, СӘНГАТЬ ҺӘМ ДИЗАЙН ФӘННӘРЕ ӨЛКӘСЕНДӘ МӘГЪЛҮМАТИ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР КУЛЛАНЫП УКЫТУ БУЕНЧА МАХСУС СЕКЦИЯЛӘР, ДӘРЕСЛӘР ОЕШТЫРЫЛАЧАК**. Кече филология һәм сәнгать институтының җитәкчеләре мәгълүмати технологияләрне тирәнтен өйрәнү максатыннан «филологиядә мәгълүмати технологияләр мәктәбе»н булдырырга карар кылган. Мәктәптә көндезге бүлектә дә, читтән торып укырга да мөмкин булачак. Мәктәп каникуллары вакытында көндезге сессияләр эшләячәк.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Әмир Фазлыйәхмәтов фотосы

# Түрәләр дә белемен күтәрә

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

Дәүләт хезмәткәрләре һәм төрле урында эшли торган җитәкчеләр укыйсын укыганнар инде дип уйлыйсызмы? Ялгышасыз... КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарә итү Югары мәктәбе нәкъ менә дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәткәрләре өчен квалификациясен күтәрү эшен алып бара. Кичә әлеге программа буенча укыган өч төркемгә сертификатлар тапшыру тантанасы узды.

«Вакыты аз шул», – дип уфтана «студентлар». Бер атнага сузылган программа бик күп төрле лекцияләрне үз эченә сыйдырган. Төркемдә Казаннан да, Татарстанның төрле районнарыннан да шактый тәҗрибә туплаган абый-апалар белән бергә яшь җитәкчеләр дә бар иде. Чарада катнашкан ТР Президенты каршындагы дәүләт хезмәткәрләре Департаменты җитәкчесе Александр Белов: «Сезнең тагын бер кат студент булу мөмкинлеге туды. Бу юлы алган белемнәрегез хезмәт юлыгызда килеп туган мәсьәләләрне уңышлы хәл иткәндә ярдәме тияр дип уйлыйбыз. Алга таба да үзара дуслыкны өзмичә, бергәләп эшләргә язсын иде безгә», – диде ул.

Программабарышындахезмәткәрләр өчен төрле тренинглар, интерактив дәресләр уздырылган. Мондый чараларда аеруча актив булганнарга ректорыбыз Илшат Гафуров исеменнән аерым рәхмәт сүзләре җиткерелде. Андыйлар арасында финанс министрлыгының белгеч-эксперты Айсылу Кузьмина да бар: «Әлеге курс профессиональ һәм гомуми үсеш өчен бик тулы һәм эчтәлекле булды. Биредә алынган белемнәр үзебезнең өлкәдә генә түгел, ә башка юнәлешләр буенча эшләгәндә дә ярдәм итәр» – дип фикерләре белән уртаклашты.

Инвестицион үсеш агентлыгының алдынгы белгече Людмила Павловага шул ук мәктәпнең «Идарә итү һәм лидерлык мәктәбе» укыту программасы җитәкчесеРевяз Шулайя рәхмәтен җиткерде. Лектор «студентлар» мәхәббәтен коммуникатив тренинглары белән яулап алган. «Күбрәк командада эшләдек. Бу безне тагын да якынайтты. Рәхәтләнеп аралаштык, фикерләребез белән дә уртаклаштык», – ди яшь белгеч. Ә мәктәп җитәкчелегенә тагын да югары үрләр һәм күбрәк гамәли дәресләр булуын теләде.

Ахыры 2нче биттә.

## • Бәйге

# Мөселман кинофестивале тәмам...

**Гөлсем АБДУЛЛИНА,**
хәбәрче

11 сентябрь көнне 8 нче Казан халыкара мөселман киносы фестивалено Пирамида күңел ачу үзәгендә йомгак ясалды. Бер атна дәвамында жюри рәисенә, килгән кунаклар һәм Казаныбыз халкына мөселманча төшерелгән фильмнарны карап хозурланырга һәм аларга бәя бирергә мөмкинлек бар иде.

Ахыры 2нче биттә.



• Безнең юбиляр

## Рифат Сверигин:
# «Мин – «Рубин»ның профессоры!»

**Әңгәмәдәш – Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

«Мактанырга яратмыйм», – ди Рифат абый. Әңгәмә вакытында да үзе турында артык ачылып китеп сөйләмәде... Кирәк тә түгел. Гомерен татар әдәбияты үсешенә, яшь буынга белем-тәрбия бирүгә багышлаган галимнең бөтен эшчәнлеге күз алдында. Август аенда үзенең 80 яшьлек Юбилеен каршы алган хөрмәтле Остазыбыз Рифат абый Сверигин – татар әдәбияты тарихына алтын хәрефләр белән кереп калырлык шәхес. Ничә буын студентларның яраткан укытучысы.

**- Рифат абый, Сезнең эшчәнлекнең беренче баскычлары, әдәбият өлкәсенә ясаган тәүге адымнарыгыз?**

- Безнең өйдә классик әдәбият күп иде. Ж.Верн, Рубинштейн, А.Пушкин әсәрләренең татарча вариантларын укып үстем. Аларны бүгенге көндә беркая да таба алганым юк, ә миндә сакланалар. Кечкенәдән үк шул классиканы күрә белгәнмен, димәк. Бу мәхәббәтем алга таба тагын да көчәйде. Югары уку йортын тәмамлагач, юллама буенча Аксубай районына туры килдем. Дөрес, колач җәеп каршы алмадылар. Тел һәм әдәбият буенча дәресләр дә аз иде, шуңа күрә миңа өстәмә география фәнен һәм немец телен бирделәр.



**- Димәк, сез әлеге фәннәр буенча да белгеч?**

- Географияне мин бик яратам. Немец телен юньләп белми идем дә. Уку башлангач, комиссия килде. Җитәкчесе – Германиядә немецлар белән эшләгән тәрҗемәче. Алар алдында бик уңайсыз хәлдә калдым. Шуннан соң районга чакырып, миңа пластинкалар бирделәр, Берлиннан немец телендә чыга торган газеталар яздырдылар. Бу минем өчен бик яхшы булды. Аспирантурага кергәндә, 1 урынга 7 кеше иде. Мин чит тел буенча имтиханнан «5»ле алдым һәм аспирант булдым. Тормышта һәр нәрсә үз урынын таба диясем килә.

**- Башка чит телләргә мөнәсәбәтегез ничек?**

- Чит телләрне өйрәнергә кирәк. Әллә ничә тел беләм димим, ләкин кызыксынам. Испан теле бик якын минем өчен. Әгәр яшь чагым булса, шул телләрне өйрәнеп, чит илгә китәр идем. Яшьләр әлеге мәсьәләгә игътибарларын күбрәк юнәлтсеннәр. Ана телен яхшы белү – зарур, ә аның янында берәр чит тел дә булса, беркая да югалмыйсың.-

**Рифат абый, Сезне гел әдәбият кына укып утыра торган кеше итеп күз алдына китерүе авыр. Тагын ниләр белән шөгыльләнәсез?**

- Мин үземне бронза медаль иясенә якын спортчы дип атар идем. Спортны яратам, карыйм, үзем дә шөгыльләнәм. Буем кыска булса да, волейбол уйнадым. Көн саен Кабан күле буйлап йөгердем, аның периметры 5 км. Хәзер инде йөгермим, ә йөрим. 6 тапкыр марафонда катнаштым (*марафонның озынлыгы – 42 км, туктамыйча йөгерергә кирәк, Д.Ә.*), шуның берсе – Мәскәүдә. Бөтен спорт тапшыруларын карыйм. Ә Казанның «Рубин» футбол командасы буенча үземне профессор дип атый алам. Гомумән, спортка, физкультурага рәхмәтем зур. Радиотехника белән бераз кызыксынам. Үзем ясаган радиоалгычлар да бар.

**– Шәхси тормышыгыз турында да әйтеп китегез әле?**

- Мин тормыш иптәшемне дә Аксубайда таптым. Бик кызыклы килеп чыкты ул. Казанда бер туташ пединститутның физика факультетын тәмамлагач, безнең мәктәпкә юнәлтелгән. Мин мәктәбебезне мактап бер газетада язма бастырган идем. Теге яшь кыз: «Татар мәктәбенә бармыйм!» – дип киреләнеп торганда: «Менә анда руслар да эшли», – дигәннәр минем фамилияне күрсәтеп. Ул безгә кайтты, кавыштык. Ике ул тәрбияләп үстердек. Берсе – Казанда җиңел атлетика буенча тренер, икенчесе Чиләбе шәһәрендә яши. 6 оныгыбыз бар, оныкчыкларыбыз да үсеп килә, Аллага шөкер.

**- Рифат абый, Сезгә 80 яшь бирүе авыр. Һәр кешенең үз яшәү сере бар. Спорттан тыш, яшәү рецептына тагын ниләр кертелгән?**

- Мин аңа үзем дә ышанып бетмим. Әле генә студент идем, әле генә яшь укытучы идем. Гомер үтә икән ул. Һәр минутның кадерен белергә кирәк. Камиллекнең очы-кырые юк. Аңа һаман омтылырга, югарыдан бирелгән көчне дөрес файдаланырга. Кешеләргә карата мәрхәмәтле булырга, ярдәм итәргә, яхшылык кылырга кирәк. Иманым камил дип йөрергә ярамый. Аның камиллеген Аллаһы Тәгалә генә белә.

**- Шулай да тормышка ашмый калган хыялыгыз бармы?**

- Мин мөмкинлегемә карап яшәдем, төрле якка сибелеп эшләдем. Бер өлкәдә генә эшләсәң, әллә нинди үрләр яулар, ләкин алай мин рухи яктан ярлы булыр идем. Аллага шөкер, алдыма куелган хыялларыма ирештем дип уйлыйм.

**- Яшьләргә, студентларыгызга нинди теләк-тәкъдимнәр җиткерәсез?**

- Тагын бер кат әйтәм: чит телләрне өйрәнегез. Машина йөртү таныклыгыгыз булсын, чөнки алдагы көндә машинасыз яшәп булмаячак. Электрониканы яхшы үзләштерегез. Интернет уен, егетләр эзләү өчен генә файдаланылмасын! Аның мөмкинлекләре чиксез зур, дөрес файдаланыгыз, ләкин ул сезнең тормышта китапны кысрыкламасын. Китап биргән ләззәтне, китап биргән байлыкны интернет бирә алмый. Исән-сау булыйк, һәр туган көнгә сөенеп яшик.

# Түрәләр дә белемен күтәрә



**Башы 1нче биттә.**

Казанбыздан иң ерак урнашакан районнарның берсе Әгерҗе районы Салагыш авыл җирлеге башлыгы Фәнис Фәхриев мондый курс оештыручыларга, укытучыларга аеруча рәхмәтле. Күп очракта мондый чараларда авыл кешеләре игътибардан читтә кала. Дәүләт һәм муниципаль идарә итү Югары мәктәбе мондый җитешсезлекләрне юкка чыгарырга тырыша. «Бик күп файдалы мәгълүмат алып, яңа законнар белән танышып кайтып китәбез. Алга таба да мондый курсларны бик теләп үтәр идек», – диде Фәнис абый.

Никадәр генә эшләсәң дә, тәҗрибә уртаклашу, гыйлем алу һәр кеше өчен кирәкле. Бигрәк тә шундый җаваплы – дәүләт хезмәткәре вазифасын башкарганда, белемне арттыру зыян итмәс.

• Бәйге

# Мөселман кинофестивале тәмам...

**Башы 1нче биттә.**

Чараның ябылу тантанасы бик тә үзенчәлекле, килгән кунакларны тәэсирләндерерлек итеп оештырылган иде. Тантананың иң көтелгән мизгелләре булып әлбәттә, катнашучыларга бүләкләр тапшыру булды.

Дөресен әйтергә кирәк, фильмнар арасында төрлесе бар: мөселман илләрендәге проблемаларны чагылдырганнары дисеңме, яшьләрнең дингә мөнәсәбәте дисеңме, билгеле бер ил культурасының үзенчәлекләрен яктырткаННары дисеңме – барсы да. Ни кызганыч, араларында гади тамашачыга бик үк аңлашылып бетмәгәннәре дә, авыррак кабул ителгәннәре дә булды. Көннәрнең яңгырлы торуына карамастан, кинотеатрда буш урыннар калмый иде.

Фестивальнең төп җиңүчесе булып «Сахра бөртеге» (‹‹Крупица сахара», Иран) фильмы танылды. Башка илдәге мөселман кардәшләребезнең шундый уңышларга ирешүенә сөенерлек, әлбәттә. Шулай да җиңүчеләр арасында Татарстан кинемотографларының хезмәтләре бик аз булуы, дөресрәге булмавы әллә ничек кенә итеп күңелне тырнап тора. Сәхнәгә рәхмәт сүзләре әйтергә менгән кунакларның һәммәсе дә Казан шәһәренең тыныч, кунакчыл, матур шәһәр булуына басым ясады. Мөгаен, бу вакытта залда утырган һәр казанлы горурлык хисләре генә кичереп утыргандыр. Алга таба да илебездә тынычлык, милләтара дуслык булуын дип, ә фестивальгә исә яңаданяңа уңышлар теләп калабыз!

• Белем баскычлары

# Алман теле - Казан теле!

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

Сез әле Казан университетында Алман мәдәни үзәгенә килеп, белемнәрегезне сынап карадыгызмы? Әллә бөтенләй дә аның барлыгын белмисездәме? Минем кебек беренче ишетүчеләр өчен мәгълүмат: 2012 елның язында Гёте исемендәге Алман мәдәни үзәге Филология һәм сәнгать институты җитәкчелеге белән берлектә КФУда белем тикшерү үзәген булдыру турында карар кылган.

Балалар өчен дә, яшьләр өчен дә беренче имтиханнар май аенда ук булды. Сынауны яхшы үтә алганнар тиздән Гёте институтының халыкара сертификатларын тантаналы рәвештә кулларына алачак.

11 сентябрь көнне КФУда Алман мәдәни үзәге «Гомуми Европа тел компетенцияләре һәм тел портфеле» дип исемләнгән семинар уздырды. Филология һәм сәнгать институтында үткән бу чара Россиянең Гёте исемендә Алман мәдәни үзәгенең фәнни-методик үзәк җитәкчеләре тарафыннан оештырылды. Семинарны Гёте исемендәге Алман мәдәни үзәгенең методист мультипликаторы, филология фәннәре докторы Светлана Тахтарова һәм Санкт-Петербургтагы Гёте исемендәге Алман мәдәни үзәгенең мәгариф өлкәсендәге белгече Бахром Султанходжаев алып барды.

Гёте Институты – Германия Федератив Республикасының мәдәни үзәге. Аның төп максаты: мәдәният өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек булдыру, Германиянең иҗтимагый-мәдәни тормышы белән даими таныштырып бару, алман телен өйрәнүне оештыру һәм гамәлгә ашыру.

Россиядә Гёте институтының мәгариф һәм мәдәният өлкәсендә тышкы сәясәт мәсьәләләре белән шөгыльләнә торган өч мәдәни үзәк бар: аларның берсе Мәскәүдә, калганнары Санкт-Петербург белән Новосибирск шәһәрләрендә. Илебезнең барлык төбәкләрендә дә Гёте институты алман телен өйрәнүдә хезмәттәшлек итә.

Семинарда катнашырга дип Рәсәйнең 20 регионыннан Алман мәдәни үзәкләренең җитәкчеләре Казан университетында җыелды. Бахром Султанходжаев сүзләренчә, семинарны уздыру урыны итеп КФУ юкка гына сайланмаган: «Казан Федераль университетының дәрәҗәсе бик югары. Алай гына да түгел, монда Россиядә иң яхшылардан саналган фәнни-методик үзәк тә бар». Көн дәвамында белгечләр телнең вазифалары, аларның функцияләре һәм төп максатларына бәйле сорауларга җавап табарга тырышты. Казанда үткән семинар алман телендә барды.



• Кечкенә галим

## Илгиз Абдуллин: «Җитәкче кеше таләпчән булсын, әмма каты бәгырьле булмасын…»

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Күптән түгел университетыбыз үсешенә зур өлеш керткән, күп еллар КДПУ да проректор булып эшләгән, бүгенге көндә универсиада авылы мэры киңәшчесе булып эшләүче Абдуллин Илгиз Абдулла улының 70 яшьлек олуг юбилее булып үтте. Шул уңайдан мин дә аның белән күрешеп, сөйләшеп алдым.



Илгиз абыйга һич тә 70 яшь бирмәссең: йөзеннән нур бөркелә, әйткән сүзләре акыллы, фикерләре төпле. Юбилярыбызның үсмер чоры хатирәләренә бергәләп барып килик әле.

«...Мәктәптә укыган чорда рус телен өйрәнү теләге көчле иде. Әмма диктант яздыра башласалар, тараканны кызылга манып дәфтәр буйлап җибәргәч, ничек чуар булса, безнең дәфтәр дә нәкъ шундый кыяфәттә була иде. Шуңа да карамастан, рус теле укытучыбыз бик сабыр, түземле булды. Алланың рәхмәтләре яусын аңа!

Җиде ел укыганнан соң, мәктәбебездә сигезенче сыйныфка кырык бер баланы гына укырга алалар. Безнең ише укырга теләкләре көчле булганнар туксангаҗитте, ләкин класслар юк. Шуннан соң белем алырга теләүчеләрнең санын киметү максатыннан, кызык кына методика уйлап таптылар: көнгә берәр дәрес укыталар да, күрше авылга бәрәңге алырга, траншея казырга һәм башка шуның ише хезмәтләргә җибәрәләр. Ашарга юк, дәресләр әзерләргә вакыт юк, ардыра... Шулай итеп селки торгач без – кырык бер бала булып сигезенчедә укып киттек...

Тагын шул мизгелләр истә калган: күрше авылга йөреп укыгач, салкын буранлы көннәрдә интернатта калырга туры килә иде. Азыкны өйдән алып бардык. Булса бер-ике кисәк ит, бәрәңге булгандыр. Бер мәлне бушлай гомуми ашату турында закон керттеләр. Зур казанда ашарга пешерәләр, итсез генә коры, бик үк тәмле булмый иде ризыгыбыз. Шуннан соң һәрберебез үзенең өйдән алып килгән ит кисәкләрен җепкә бәйләп, кырыена исем фамилияне язып, шул казанга төшерә башладык. Пешеп чыккач, иң тәмлесе нәкъ менә шул җеп белән тартып чыгарган калҗа була иде.



Иң якты, иң татлы хатирәләремнең берсе ул – сәгатьле булуым! Саба районындагы хәллерәк кешеләргә утын ярып, вактөяк эшләрен башкарып тапкан акчага алынды ул. Шуннан соң ул сәгатьне күрсәтебрәк, күлмәк җиңе өстенә чыгарыбрак куеп йөрдем. (*Фотода да шул сәгатьне күрсәтеп төшкән Илгиз абый.-З.Ф.*)

Гомеремнең күпчелек өлеше тулай тораклар өлкәсендә хезмәт куеп үтте. Язмышыма шулай язылгандыр, үзем Казанга килеп укырга кергәч, беренче курста миңа тулай торак җитмәде. Шуннан соң апаларга киттем. Аларның Аракчинодагы баракларында бик тә тыгыз. Мине барак янындагы бер чоланга урнаштырырга булдылар. Алдан суыкларга ничек түзәрмен дип уйладым, ләкин монысы гына куркырлык нәрсә булмаган әле. Төнлә белән йокларга яткач, өстемнән зур-зур күселәр чабыша иде. Икеөч ай юрган эчендә йоклап, сулыш алырга да куркып һәм чабулап йөргән күселәрне сизгән хәлдә шул чоланда яшәдем. Бу миңа гомерем буена җитәрлек дәрес булды. Җитәкче булып эшли башлагач та, студентларның барысын да ничек тә тулай тораклы итәсем килде. Чөнки үзем тормышның бу мәктәбен үткән кеше – балаларның хәленә кермичә берничек тә булмый. Гомумән, җитәкче булып эшләүче кеше ул таләпчән булсын, әмма каты бәгырьле булырга һич ярамый. Кеше хәленә керә белергә кирәк... Студентларга да, укучыларыма да ул сүзләрне һәрчак кабатлыйм: кешелекле булсыннар, нәрсәгә булса да ирешергә теләсәләр ялкаулыкларын җиңәргә өйрәнсеннәр...».

***P.S.*** *Илгиз абый белән әңгәмәкорганда, вакытның үткәне сизелмәде дә. Акыллы сүзләре минем дә күңелемә уелып калды. Ә без үз чиратыбызда, Илгиз Абдулловичны юбилее белән тәбриклибез. Һәр елның үз истәлеге, онытылмас мизгелләре була! Сезгә дә уфтанмыйча, тормышның һәр көненнән ямь, матурлык табып, исәнлектә-саулыкта яшәвегезне теләп калабыз!*

• Әллүки тәрәзәсе

## «Әллүки»дә – Нурания Җамали





**Булат ИБРАҺИМ,**
татар филологиясе бүлеге студенты

Иҗат белән янып йөрүче студентлар үзләрендә «Яңа Гасыр» телеканалы режиссеры, Татарстанның атказанган артисты Нурания Җамалине кунак итте. 6 сентябрь көнне Филология һәм сәнгать институтында «Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсенең яңа уку елындагы беренче утырышы әнә шулай узды.

«Әллүки» әдәби-иҗат берләшмәсендә яшь шагыйрь-шагыйрәләр, прозаиклар күпчелекне, ә драматург-сценаристлар азчылыкны тәшкил итсә дә – татар киносы, татар телевидениесе турындагы сөйләшү һәркем өчен дә кызыклы, файдалы һәм мавыктыргыч булды.

«Әлли-бәлли-бәү» тапшыруында алып баручы булган Нурания апа тамашачыларга татар телевидениесендә балалар өчен музыкаль фильмнар режиссёры буларак таныла башласа, хәзерге вакыттагы иҗаты салмак кына зуррак сәнгать әсәрләренә җан өрә: «Кешечә яшик», «Яланаяклы кыз», «Өч аяклы ат», «Тузган торгантан күчкәндә», «Уеннан уймак» һ.б. фильмнары шуның дәлиле булып тора.

Нурания Җамали сүзләреннән күренгәнчә «татар кино сәнгате җитәрлек дәрәҗәдә финансланмый. Бу, әлбәттә, Россия һәм чит ил кино сәнгатеннән бик күп артта калуны күрсәткән факторларның берсе». Шуны да искәртергә кирәк, татар режиссёрлары үзләре дә бармак белән генә санарлык бит. Нурания Җамалидан кала бу исемлектә Рамил Төхвәтуллин, Илдар Матуров, Илдар Ягъфәров һәм ... бетте дә.

«Яңа Гасыр» режиссёрының «телеканалда сезгә нәрсә ошамый, нәрсәне үзгәртер идегез?» дигән соравына, студентларның күпчелеге татар теленә тәрҗемә ителгән кинофильмнар һәм мультфильмнардан зарланды.

Кичә-утырыш тәмам булгач, Нурания апа «Әллүки»нең «Кунак альбом»ына студентларга һәм гомумән иҗатка гашыйк булучыларга үзенең иң изге теләкләрен язып калдырды.

Иң мөһимен әйтергә онытканмын, «Әллүки» – әдәби-иҗат берләшмәсе булгач, әлбәттә, Нурания Җамали студентларны иҗади биремсез калдыра алмады. «Яңа Гасыр» телеканалының шигырь сөюче тамашачылары «Ач, шигърият, серләреңне!» тапшыруын яратып карый, ә проза яратучылар өчен андый тапшыру юк. Якын арада зәңгәр экраннарда андый тапшыру пәйда булачак, ләкин нинди исем куярга? Студентлардан яңа тапшыруга исем уйлап килергә кушылды. Иң оригиналь исем уйлап табучыга «Яңа Гасыр» телеканалыннан бүләк тә тапшырылачак. Тагын бер иҗади бирем булып, Нурания апа сөйләгән сценарийның дәвамын уйлап бетерергә иде. Бу сценарий ни турында? Ул яңа татар киносының нигезенә ятачакмы? Аның ахыры ни белән бетә? Җавабын белергә теләсәң, «Әллүки»нең чираттагы утырышына рәхим ит! Керү иркле.

• Сәламәтлек

## Күз: депрессиягә вакыт юк!

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

Көз һәр кешедә төрле хисләр уята: кемдер аны бик шатланып көтеп ала, ә кемнәрдер өчен ул тискәре тойгылар, хыяллар җимерелү белән күзаллана. Статистика буенча, һәр өченче Россия кешесе көзге депрессиягә бирелүчән. Ямьле җәй артта калды, кояш инде җылысын бүләк итми, көннәр кыскара бара, алда озын буранлы-карлы кыш айлары, аяк астында былчырак, күк йөзе вак һәм салкын яңгыр тамчыларын коеп кына тора – болай булганда ничек инде төшенкелеккә бирелмисең дә, сагышланып утырмыйсың ди!..

Андый моңсу, боек күңел белән ерак китеп булмый. Әле ярый көзге депрессиядән чыгу, аның белән көрәшү юллары бар. Берничә кагыйдәне генә үтәү бер дә авыр булмаячак, киресенчә, алар безгә яхшы кәеф, күтәренке рух өстәячәк.

Иң беренче чиратта, саф һавада йөрергә, көн яктысыннан мөмкин кадәр күбрәк файдаланып калырга киңәш ителә. Болытлы көннәрдә һәм тәүлекнең караңгы өлешендә безнең организм мелатонин дигән гармон эшләп чыгара. Нәкъ менә ул депрессия өчен җавап бирә дә инде. Ультрашәмәхә нурлар исә, бу процессны әкренәйтү сәләтенә ия, шулай булгач, буш вакыт булган саен саф һавага чыгабыз, дуслар!

«Хәрәкәттә – бәрәкәт» дип тә юкка гына әйтмәгән татар халкы. Физик активлык вакытында каныбызга эндорфиннар бүленеп чыга, аларны «бәхет гармоннары» дип тә йөртәләр. Бәхетле буласыбыз килсә, иренмибез: һәр иртә саен ун-унбиш минутлык гимнастика ясыйбыз да көне буена җитәрлек энергия алабыз.

Спорт белән шөгыльләнгән арада дөрес туклану турында да онытырга ярамый. Безгә һәрдаим витаминнар кирәк, шулай булгач көн саен 300-400 г җиләк-җимеш, яшелчә ашыйбыз. Бигрәк тә А һәм С витаминнарына организмыбыз сөенәчәк.

Күңелсез көннәрне буяулар ярдәмендә ямьләндереп җибәрергә була. Төсләр белән дәвалану – фәнни нигезләнгән факт. Урамда салкын һава торышы торганда кызыл төс ярдәмгә килә. Ул йөрәк тибешен тизләтеп, тән температурасын күтәрергә сәләтле. Сары төс, мәсәлән, фикер сөрешен һәм иҗади активлыкны арттырырга, стресстан котылырга ярдәм итә. Зәңгәр төс исә, тынычландыра, уңайлы һәм киеренкесез халәт тудыра.

Үз эчеңә бикләнүне депрессия көтеп кенә тора, моңа һич тә юл куярга ярамый! Шулай булгач, дуслар-туганнар белән аралашабыз, кунакларга йөрибез, вакытны күңелле үткәрәбез, күңелгә хуш килгән эшләр белән генә мавыгабыз.

Күрүебезчә, депрессиядән котылу юллары бихисап, исемлекне әллә никадәр дәвам итеп булыр иде. Кайберәүләрнең махсус ысуллары да бардыр, кемгә нәрсә ошый бит. Ничек кенә булмасын, кәефләрне гел күтәренке тотабыз, көнозын яхшы әйберләр турында гына уйлыйбыз, кызыклы эшләр белән шөгыльләнәбез, бер-беребезгә елмаеп йөрибез. Шулай булганда депрессиягә бирелеп утырырга вакыт та калмаячак!

Әкәмәт

# Өйгә кайтып барышлый
## яки мин ничек шимбә көнне дәрес калдырмый башладым…

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

*(юмореска)*



Шимбә көненә булган парларны тозларга яратам мин. Әллә нигә җомга кайтып китәргә кыстый эчтәге «мин». Узган атнада да тиз генә кайтып китим дигәндә дә, һәр атна саен төгәл сәгать уникедә булган автобусымның кичкә табарак кына кузгаласы ачыкланды. Хи, аптырап тора торган халыкмыни без студентлар!!! «Атып калганчы-ятып калыйм», Арча кырында берәр нәрсә очрар әле дигән өмет белән юлга чыктым. Хәерчегә җил каршы шул. Озак көттем маршруткамны, нәкъ менә миңа кирәк булганда гына «кызыл тараканнарның» тиешлесе күренмәде. Әһә, ниһаять, унлы килә бугай... Ярты сәгать дигәндә мин инде Арча кырында идем... Аллага шөкер, озакламый өйдә булачакмын дигән хыялларны җитәкләп таксига утырдым... Утырдым шул, кузгалып киттек, дип әйтергә тел кычытып торса да, нәкъ менә утырдым… Таксида шактый гына халык җыелган, минем артта ике егет, янда 2-3 яшьлек улы белән яшь ханым һәм күзләрен йомар-йоммас утыручы апа иде. Кузгалыр өчен бер кеше җитми! Менә сиңа менә! Тиз генә кайтып китү иде бит бөтен уем. Әмма шактый көтәргә туры килде. Ә сәгать инде бишенче яртыны күрсәтә, бер кеше һаман юк та юк!.. Аның сәбәбе бик гади – җомга кеше аз йөри. Шимбә кайтсам да берни булмый иде бит... Ярар, кайтырга булгач, кайтырга инде. Әкрен генә салондагыларны күзәтергә керештем. Минем артта баручы ике егет нәрсә турындадыр бәйнә-бәйнә сөйләшәләр иде:

- Маратны бер кызык иттем бит әле!!!

- Чынла-ап? Я-ле сөйлә!!!

- Мин ул ботаникны парлардан чыгып китәргә мәҗбүр иттем бит әле! Ышанмассың!

Кыскасы, болай булды: телефонын кулга төшердем дә мин моның, «матурым» никнеймы белән язылган сөйгәненең номерын бетереп үземнекен язып куйдым.

- Шуннан?!

- Шуннан шул! Җибәрәм мин моңа смслар, имеш сагынам, имеш сөям! Ул да яза мәш килеп. Мин шалтыратам – ул бермәлне телефонын алып чыгып китте. Ә мин шалт бастым. Ул әйләнеп кереп җитте. Марат аудиториягә яхшылап кына гафу сорап кереп урнашты да, «матурым»ы тагын шалтырата башлады бит!!! Ул чыга – мин өзәм, ул чыга – мин өзәм... Шулай йөри торгач, лектор чыгарып җибәрде үзен!

- Менә сиңа мә!!!

Шул урында берсенең телефоны шалтыратты да әңгәмәләре өзелеп китте. Вәт кызык инде бу егетләр, берсеннән-берсе көләргә генә булсын! Ә такси һаман кузгалмый. «Берәүне» көтә... Ул мәлдә каршы якта утырган апа алга иелеп, җиңел машиналарда башын бертуктаусыз селкетеп торган уенчык бульдогны хәтерләтеп, бер сулга, бер уңга авыша иде. Шул вакыт кичке якта булырга тиешле автобусым да такси яныннан чыжылдап узып китте!

Минем ачуым тагын да кабара төште. Янымда утырган абзый да моңаеп, уйланып утыра, мөгаен аның да ачуы киләдер инде. Кайчаннан бирле әнисен аптырата алмыйча азапланган бала шулчак әнкәсеннән: «Әни, теге абый нигә колготки кимәгән. Аңа салкын түгелмени?» – дип сорап куймасынмы, абзыйның тез башыннан модалы итеп кенә өч җирдән ерылган джинсы чалбарыннан күренеп торган аякларына төртеп. Уйланып барган абзыкай да ирексездән елмаеп куйды. Менә бит, кечкенә булуына карамастан, балалар ничек уйлыйлар, туңмыйммы дип кайгырта бит әле хәтта! Инде шулай елмаешып бер-беребезгә ияләшә башлаган мәлдә, ниһаять, көткән кешебез дә пәйда булды. Без кузгалдык...

Аллага шөкер, тугызынчы киткәндә мин инде өйдә идем. Әйе шул, көн дә ике сәгатьлек юлны алты сәгать кайтмыйм бит! Әни әйтмешли, парларны тозламаска сабак булыр инде. Ходай җибәргәндер җәзасын... Шуннан бирле шимбә парлары үз вакытында укылып бара башлады.

Спорт

# Көндәшләрне яшен сукты!

**Рифат СӘЛАХ**

11 сентябрь көнне футбол буенча Россия җыелма командасы Тель-Авивта Израиль җыелмасы белән көч сынашты. 2014 елда үтәчәк футбол буенча дөнья чемпионатына чыгу өчен көрәштә Россия тагын бер адым алга атлады. 7 сентябрьдә илебез җыелмасы Мәскәүдә Төньяк Ирландия командасын 2:0 исәбе белән җиңгән иде.




Уен башында ук Россия командасы өстенлеге күзгә күренерлек иде. Беренче карашка илебез уенчылары артык бернәрсә дә эшләмәде кебек. 7 нче минутта Александр Кержаковның штраф тибүе голга әверелде. 18 нче минутта Александр Кокорин исәпне безнең файдага 2:0 итте. Ләкин бу гол кергән чакта, Владимир Быстров көндәшләрнең ике сакчысы арасында калу сәбәпле җәрәхәтләнде. Шунысы кызык, баш тренерыбыз Фабио Капеллога бу уенда кемне алыштырыйм дип баш ватасы булмады. Быстровны Александр Самедов алыштырды, 34 нче минутта аягын имгәткән Кокорин урынына Виктор Фәйзуллин чыкты.

Икенче тайм башлануга Александр Анюков та имгәнде. Аның урынына Андрей Ещенко мәйданга чыкты. Мәйдан хуҗалары исә үз капкасына керәчәк тупларны күреп бетермәгән иде шул. 64 нче минутта Кержаков, 78 нче минутта Фәйзуллин керткән голлар Израиль җанатарларын матч беткәнче үк чыгу юлын карарга мәҗбүр итте. Матч 0:4 белән кунаклар файдасына тәмамлангач, Тель-Авив стадионы яшен сукkандай тын иде.

Шулай итеп, 2014 елгы дөнья чемпионаты квалификациясенең F төркемендә Россия командасы Португалия җыелмасы белән ике уеннан алтышар очко туплап, беренче урынны бүлешә. Бу көндәшләр тиздән 12 октябрьдә Мәскәүдә үзара уйнаячак.

Ял сәгате



**Динара ӘХМӘТОВА,**
**Рифат СӘЛАХ** бергәләп төзеде.

1. Ике пар арасында буш дәрес.
2. Товарны читтән кертү.
3. Тәһарәт коралы.
4. Фәнни- ... конференция.
5. Яңа ел, 8 Март.
6. Җылы, йомшак, әбиләр бәйли.
7. Атнаның бишенче көне.
8. Тиле, акылга зәгыйфь.
9. Сәхнәдә куела.
10. Тукыма төре.
11. Чәчәк тә, кызлар исеме дә.
12. «Атла!» фигыленең киресе.
13. Тук-тук ... , тукылдатып утырам.
14. Шалаш, иске йорт.
15 (уңнан сулга). Татарстанның халык артисты Рәшит ... .
15 (өстән аска). Шагыйрьнең иҗат әсәре.
16. Бер үк төрле (фән телендә).
17. Билге, “таможня” сүзенең тамыры.
18. Җылы түгел.
19. Илшат Гафуров.

Җавапларны газетабызның электрон почтасына язып җибәрегез. Иң беренче дөрес җавап бирүчене бүләк көтә!

Кети-мети

*Имтиханда студент тиз генә бер билетны ала да,кире куя.*

*Укытучы ачулы кыяфәт белән:*

*- Нигә сез билетны куйдыгыз?*

*- 13 нче билет иде ул. Ә мин ырымнарга ышанам.*

*- Юкны сөйләмә,– профессор тиз генә 13 нче билетны тартып чыгара. Студент җиңел генә җавап бирә дә бишле алып чыга.*

*Иптәшләре, ничек бишле алдың дип гаҗәпләнә:*

*Студент:*

*- Юк,13 нче билетны гына өйрәнгән идем...*

***

*Филология факультетына кабул итү имтиханнары бара.*

*- Пушкинның «Евгений Онегин»ыннан бер өзек сөйләгез.*

*- Минем абыем ректор...*

*- Рәхмәт, Сез кабул ителдегез.*

***

*Кешеләрне бернәрсә дә контроль эштәге бер вариант кебек берләштерми!*

***

*Дәрестән арып кайтып килүче студент, тулай торакның тугызынчы катына менгәндә,борынын кытыклап кергән кыздырылган тавык исенең нәкъ менә үз бүлмәләреннән килүенә иң соңгы мизгелгә кадәр ышана иде...*

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рифат Гали улы Сәлахов
Иҗат коллективы: Д.Р.Әхмәтова, А.Ю.Садыйкова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.